КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1752

«Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 28 октябрендәге 864 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 28 октябрендәге 864 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат үзәге турындагы Положениегә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 7 август, 674 нче; 2013 ел, 14 февраль, 103 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 936 нчы; 2014 ел, 9 июль, 479 нчы; 2016 ел, 27 сентябрь, 686 нчы; 2017 ел, 1 ноябрь, 830 нчы; 2017 ел, 12 декабрь, 976 нчы; 2019 ел, 23 июль, 618 нче; 2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче; 2021 ел, 27 март, 177 нче, 2023 ел, 17 август, 983 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «а» пунктчасының икенче абзацында «(алга таба - Рәсми портал)» сүзләрен өстәргә;

9 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

«17. Рәсми портал составына керүче «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба - «Интернет» челтәре) сайтлар (алга таба - Сайтлар) дигәндә аларга керү «Интернет» челтәре аша TATARSTAN.RU, ТАТАРСТАН доменнлы зоналарда өченче дәрәҗәдәге домен исемнәре буенча гамәлгә ашырыла торган «Интернет» челтәре сайтлары, шулай ук Рәсми портал составына кертелгән «Интернет» челтәрендәге башка сайтлар аңлашыла.

Сайтлар республика башкарма хакимияте органнары, башка дәүләт органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар (алга таба - Катнашучы оешмалар) тарафыннан мөстәкыйль рәвештә идарә ителә.

Хокукый актларны исәпкә алып, Катнашучы оешмалар мөстәкыйль рәвештә һәм үзләре теләгәнчә Сайтларда мәгълүмат урнаштыру тәртибен билгелиләр.

Сайтны администрацияләү үз эченә ала:

Сайтта бастырыла торган мәгълүматны билгеләүне һәм әзерләүне;

Сайтта мәгълүматны Рәсми порталның программа чаралары (идарә итү системасы) белән бастырып чыгару һәм яңарту;

Катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган файдалану хокуклары кысаларында Рәсми порталның программа чаралары белән (администрацияләү системасы) Сайт белән идарә итү һәм аны җайга салу;

Сайтның битенең структурасын һәм исемлеген Рәсми порталның программа чаралары (администрацияләү системасы) белән билгеләү;

Сайт белән идарә итүне гамәлгә ашыру, анда мәгълүматны бастырып чыгару һәм яңарту өчен автоматлаштырылган эш урынын җайга салу (шул исәптән кирәкле җиһазларны, элемтә чараларын һәм программа белән тәэмин итү чараларын);

Сайтта мәгълүмат урнаштыру өчен җаваплы Катнашучы оешма хезмәткәрен билгеләп кую (алга таба - оператор-хезмәткәр);

оператор хезмәткәрләрнең Сайт бүлекләренә керү хокукын билгеләү өчен җаваплы Катнашучы оешма хезмәткәрен билгеләп кую;

Сайтка ярдәм итү өчен җаваплы Катнашучы оешма хезмәткәрен билгеләү.

Катнашучы оешма «Интернет» челтәреннән файдаланучылар Сайтка мөрәҗәгать итү нәтиҗәсендә алынган шәхси мәгълүматлар операторы булып тора, һәм мондый шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатларын, шәхси мәгълүматлар составын, шулай ук шәхси мәгълүматлар белән башкарыла торган гамәлләрне (операцияләрне) билгели.

Катнашучы оешма түбәндәгеләргә бурычлы:

Сайтта бастырылган мәгълүматның законнар таләпләренә туры килүен, мондый мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тәэмин итәргә, шулай ук физик һәм юридик затларның хокукларын бозуны булдырмаска. Сайтта басылган мәгълүмат өчен Катнашучы оешма җаваплы;

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматлар операторы йөкләмәләрен үтәргә;

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә карата Катнашучы оешма сәясәтен билгели торган документны һәм шәхси мәгълүматны яклауга гамәлгә ашырыла торган таләпләр турында белешмәләрне администрацияләнә  торган Сайтта бастырырга, шулай ук «Интернет» челтәре чараларын кулланып әлеге документка керү мөмкинлеген тәэмин итәргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин